Р Е С П У Б Л И К А
Т А Т А Р С Т А Н
**СОВЕТ**
**Большесалтыковского**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**м у н и ц и п а л ь н о г о р а й о н а**

ул.х.Такташ, 132, с.Большие Салтыки, 422831
тел. (8437) 35-8-19 факс: (8437) 35-8-19
ИНН 1622001869

Т А Т А Р С Т А Н
Р Е С П У Б Л И К А С Ы
**Кама Тамагы**
**м у н и ц и п а л ь р а й о н ы**
**Олы Салтык авыл жирлеге**

**СОВЕТЫ**

Х.Такташ урамы, 132, Олы Салтык авылы., 422831,
тел. (8437) 35-8-19 факс: (84377) 35-8-19
ИНН 1622001869

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15.11.2019** **№ 51**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2019 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылы торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән,кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 (өч йоз) сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме”:

- Даныш авылында кулне чистарту;
- Даныш авылында каты көнкүреш калдыклары полигонын норматив хәлгә китерү.

**«ӘЙЕ»** **«ЮК»**

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 3(өч) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы**
**муниципаль районы Олы Салтык авылы**
**җирлеге башлыгы** **Х.Х. Ибәтов**